СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Решение** **Карар**

№ 11-6 от «14» апреля 2026 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2021 елның 12 ноябрендәге «Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 8-9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 30 сентябрендәге 1670 номерлы карарына үзгәреш кертү турында»Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 12 ноябрендәге 1783 номерлы карары, Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2021 елның 12 ноябрендәге «Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 8-9 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктның 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затлар, региональ операторлар, төзүчеләр, күпфатирлы йортка турыдан-туры идарә итүне гамәлгә ашыручы күпфатирлы йорттагы урыннарның милекчеләре белән карап тоту һәм (яисә) үтәү буенча хезмәтләр күрсәтү шартнамәләре төзелгән, күпфатирлы йортта урыннарның мондый милекчеләре тарафыннан торак-коммуналь хуҗалык системасында мәгълүмат урнаштыру хокукы бирелгән затлар тарафыннан торак-коммуналь хуҗалык системасында мәгълүмат урнаштыру тәртибенә таләпләр ;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://madysh.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башлыгы урынбасары Р.Р. Самигуллинга йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Башлыгы В.И.Никитин

000025